ГАУЗ «Апастовская ЦРБ»
Вх. № 550
«31» июля 2019 г.

Рәхмәт хаты

Олы Бакырчы авылында яшәүче әниебез Сибгатуллина Гөлфат Зәйдулла кызы авырып китте. Өйдә дәвалау курсларын үтеп тә алга үзгәреш булмагач, Апас үзәк хастахәнәсенә алып килдек. Машина килеп туктаганда табиблар иртәңге киңәшмәдән таралыша иде. Үз эшенең чын остасы булган, мәрхәмәтле табиб Хураскин Алик Алексеевич шунда ук ярдәмгә килде. Тиз генә әниебезне ашыгыч ярдәм бүлегенә алып керде. Шул арада барлык анализларны да алдылар. Анализлар өлгергәч, әниебезгә дөрес диагноз куеп, талантлы табиб-терапевт Хураскин Алик Алексеевич бүлек мөдире Райлә Хәмзә кызы Хасанова белән киңәшләшеп дәвалау курсын билгеләделәр һәм палатага урнаштырдылар. Хастанәдә чисталык, тәртип, заманча аппаратлар. Иң мөһиме шифалы куллары, ягымлы йөзләре, күңелләрен биреп, җаны-тәне белән, булсын диеп эшләүче Алик Алексеевич кебек табиблар, шәфкать туташлары эшли биредә. Аллага шөкер, әниебез дәвалау курсларын үтеп, терелеп өйгә кайтты.

Әниебезгә күрсәткән һөнәри осталыклары өчен Алмаз Алиуллин җитәкчелегендәге Апас районы үзәк хастахәнәсе коллективына, аеруча терапия бүлегенә, Хураскин Алик Алексеевичка олы рәхмәтебезне белдерәбез. Кешелеклелегез, олы йөрәгегез өчен зур рәхмәт сезгә. Нык сәламәтлек, куйган максатларыгызга һәм бурычларыгызга ирешүегезне теләп калабыз.

Ихтирам белән кызлары Гөлфинә, Гүзәл, Гөлгенә, Алсу гаиләләре.